Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

6 июнь, 2023 ел № 6

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башлыгының Питрәч авыл җирлеге башлыгы «Мелиораторлар урамындагы аз катлы күп фатирлы торак төзелеш җир кишәрлекләрен шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында» карар проекты буенча Питрәч авылында иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советының 2017 елның 18 августындагы 65 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегендә (2017 елның 15 декабрендәге 79 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 92 номерлы, 2019 елның 08 октябрендәге 137 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 60 номерлы үзгәрешләре белән) иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә, кергән гариза нигезендә карар бирәм:

1. «Мелиораторлар урамындагы аз катлы күп фатирлы торак төзелеш җир кишәрлекләрен шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башлыгы карары проекты буенча Питрәч авылында иҗтимагый фикер алышуларын билгеләргә (алга таба - Проект) (кушымта).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия);

2.2. Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны - 2023 елның 15 июнендә, 10.30 сәгатьтә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының кече залында, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Питрәч ав., Совет ур., 18 нче йорт адрес буенча;

2.3. авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла ала торган адрес - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы: 422770, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авыл җирлеге, Питрәч ав., Совет ур., 18 й. адресы буенча (дүшәмбе-җомга

8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр төшке аш тәнәфесе 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

2.4. Питрәч авыл җирлеге халкына җиткерү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында проектларның демонстрацион материаллары күргәзмә-экспозициясен оештырырга, адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Совет урамы, 18 йорт (дүшәмбе-җомга 8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты - 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

3. Комиссиягә:

3.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру йомгаклары буенча иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсе, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләргә;

3.2. Иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен Питрәч муниципаль районы Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга;

3.3. «Вперед» («Алга») газетасында иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында хәбәрне бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы — И.М. Кашапов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Питрәч авыл җирлеге
башлыгы карарына кушымта
6 июнь, 2023 ел № 6

ПРОЕКТ

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

___ __________ 2023 ел №__

«Мелиораторлар урамындагы аз катлы күп фатирлы торак төзелеш җир кишәрлекләрен шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында»

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенең 2023 елның __.____. 2023 елгы җәмәгатьчелек фикер алышулары нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә әзерләнгән тәкъдимнәрен исәпкә алып карар бирәм:

1. Җир кишәрлекләрен шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирергә:

- ж/к кадастр номеры 16:33:120113:866, мәйданы 2 035 кв.м., адресы: ТР, Питрәч районы, Питрәч авыл җирлеге, Питрәч авылы, Мелиораторлар ур., 31 й. - «Аз катлы күпфатирлы торак төзелеше» шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1)

- ж/к кадастр номеры 16:33:120113:867, мәйданы 1 111 кв.м., адресы: ТР, Питрәч районы, Питрәч авыл җирлеге, Питрәч авылы, Мелиораторлар ур., 39 й. - «Аз катлы күпфатирлы торак төзелеше» шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1)

- ж/к кадастр номеры 16:33:120113:39, мәйданы 2 035 кв.м., адресы: ТР, Питрәч районы, Питрәч авыл җирлеге, Питрәч авылы, Мелиораторлар ур. - «Аз катлы күпфатирлы торак төзелеше» шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.